**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 сентябрь 2026 ел № 1123

**«2026 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. «2026 – 2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын төзегәндә Программа чараларын бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм бу максатларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган акчалар чикләрендә гамәлгә ашыруга акча бүлүне карарга.
3. Бу карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин